ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 10-61/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарлары үз көчләрен югалтуны тану турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) көчен югалтуын тану турында» 2014 елның 29 декабрендәге 458 номерлы Федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге караларының үз көчләрен югалуын таныргa:

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «Төзекләндерү» ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 20.02.2015 № 10-2/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «ЭкоСистемы» ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 13.03.2015 № 10-6/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «Әгерҗе муниципаль районы төзелеш идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 10.04.2015 № 10-8/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «ТКХ (Инженерия челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 29.05.2015 № 10-10/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «Балык Бистәсе торак-коммуналь сервисы» ҖЧҖ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 10.07.2015 № 10-16/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча «Таткоммунэнерго» РҖБ АҖ тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2015-2018 елларга тарифлар билгеләү турында» 07.08.2015 № 10-20/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәче компаниясе» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2016-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 26.08.2016 № 10-9/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 №10-19/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча хезмәтләргә 2017-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 №10-20/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча хезмәтләргә 2017-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 №10-21/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча хезмәтләргә 2017-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 №10-22/кс;

“Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча «Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 17.03.2017 № 10-4/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча «Торак хуҗалыгының һәм төзекләндерүнең күптармаклыҗитештерү берләшмәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2021 елларга тарифлар билгеләү турында» 24.03.2017 № 10-6/кс;

«Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, йогышсызландыру һәм күмү буенча «Чирмешән районы коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2017-2020 елларга тарифлар билгеләү турында» 25.08.2017 № 10-20/кс.

2. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов